**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тәмте авыл җирлеге Советы Карары**

**“31” июль 2019 ел** **№ 127**

2013 елның 17 декабрендәге “Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы Тәмте авыл җирлеге”
муниципаль берәмлегендә җирдән файдалану һәм
төзелешләр кагыйдәләрен раслау турында”гы 87 номерлы
Карары турында”гы Татарстан Республикасы Кама
Тамагы муниципаль районы Тәмте авыл җирлеге
Совет Карарына үзгәрешләр кертү турында”гы
Карар проекты турында

2019 елның 27 февралендәге “Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында”гы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 133 нче Карары нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге Советы **КАРАР КЫЛДЫ**:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тәмте авыл җирлеге Советының 2013 елның 17 декабрендәге 87 Карары белән расланган “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге җирләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- 33 маддәнең 5 пунктында “торба үткәргечләрнең саклау зоналарындагы җирләрдән файдалану тәртибе” (Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының нче 2007 елның 20августындагы 395 номерлы Карары белән расланган) сүзләрен төшереп калдырырга;

- 36 маддәнең 2 пунктындагы 12 абзацын төшереп калдырырга;

- 36 маддәнең 5 пунктында “торба үткәргечләрнең саклау зоналарындагы җирләрдән файдалану тәртибе” (Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының нче 2007 елның 20августындагы 395 номерлы Карары белән расланган) сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге Карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда игълан итәргә:

- ТР, Кама Тамагы районы, Тәмте авылы, Октябрь урамы, 65 йорт ( авыл җирлеге хакимияте бинасы);

- ТР, Кама Тамагы районы, Тәмте авылы, 2 нче Октябрь урамы, 50 нче йорт ( мәдәният йорты бинасы),

шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтының “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Кама Тамагы муниципаль районы Тәмте авыл җирлеге Башлыгы, Кама Тамагы муниципаль районы Тәмте авыл җирлеге Советы рәисе** **И. А. Зиновьев**